хезмəттəшлектə катнашучыларның санкциялəнгəн файдалана алуын тəэмин итə торган федераль дəүлəт мəгълүмат системасы;

КФҮ – «Татарстан Республикасында дəүлəт һəм муниципаль хезмəтлəр күрсəтүнең күпфункцияле үзəге» дəүлəт бюджет учреждениесе;

КФҮ АМС – Татарстан Республикасы дəүлəт һəм муниципаль хезмəтлəр күрсəтү күпфункцияле үзəклəренең автоматлаштырылган мəгълүмат системасы.

1.5.2. Административ регламентта муниципаль хезмəт күрсəтү турында гариза (алга таба – гариза) дигəндə «Дəүлəт һəм муниципаль хезмəтлəр күрсəтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендəге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясы 3 пункты нигезендə муниципаль хезмəт күрсəтү турында гариза аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмəт күрсəтү стандарты

### 2.1. Муниципаль хезмəтнең исеме

Белешмə (өземтə) бирү.

### 2.2. Җирле үзидарəнең муниципаль хезмəтне турыдан-туры күрсəтүче башкарма-боеру органы исеме

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты

### 2.3. Муниципаль хезмəт күрсəтү нəтиҗəсенең тасвирламасы

2.3.1. Муниципаль хезмəт күрсəтү нəтиҗəсе булып тора:

1) белешмə (өземтə) (əлеге административ регламентка 1 кушымта);

2) муниципаль хезмəт күрсəтүдəн баш тарту турында карар (əлеге административ регламентка 2 кушымта);

3) муниципаль хезмəт күрсəтү өчен кирəкле документларны кабул итүдəн баш тарту турында карар (əлеге административ регламентка 3 кушымта).

2.3.2. Муниципаль хезмəт күрсəтү нəтиҗəсе мөрəҗəгать итүчегə «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендəге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендə Башкарма комитетның вəкалəтле вазыйфаи затының (яки Башкарма комитетның) көчəйтелгəн квалификацияле электрон имзасы белəн имзаланган электрон документ формасында Бердəм порталның шəхси кабинетына җибəрелə. Гариза Республика порталы аша җибəрелгəн очракта, муниципаль хезмəт күрсəтү нəтиҗəсе шулай ук Республика порталының шəхси кабинетына җибəрелə.

2.3.3. Мөрəҗəгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмəт күрсəтү нəтиҗəсе Башкарма комитетта яисə КФҮдə кəгазьдə бастырылган, тиешле Башкарма комитетның вəкалəтле вазыйфаи заты яки КФҮ хезмəткəренең мөһере һəм имзасы белəн таныкланган электрон документ нөсхəсе формасында бирелə.

